**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «06» сентябреннән                                                                 № 36-295

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын ясау һәм алып бару тәртибе турында» 2016 елның 30 декабрендәге 21-112 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, «Муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару турында» Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы президиумының 2016 елның 13 октябрендәге ПР-26-4 номерлы карарын игътибарга алып, Татарстан Республикасы муниципаль районының Яңа Чишмә муниципаль районы Уставына таянып, җирле үзидарә органнары кабул иткән норматив хокукый актларны исәпкә алуны камилләштерү, унификацияләү һәм системалаштыру, аларның эшчәнлеге турында мәгълүматның ачыклыгын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын ясау һәм алып бару тәртибе турында» 2016 елның 30 декабрендәге 21-112 номерлы карарына (Советның 2019 елның 16 декабрендәге 55-348 номерлы, 2023 елның 12 июлендәге 35-284 номерлы карарлары редакциясендә) (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктында:

«баш белгечне (юристны)» сүзләреннән соң «, ә ул булмаганда башлыкны» сүзләрен өстәргә;

«һәм Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының эшләре белән идарә итүчесе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетын (алга таба - район Башкарма комитеты), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасын (алга таба - район ПИЗОсы), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасын (алга таба - район ФБПсы). Районның башкарма комитетына, районның ПИЗОсына, районның ФБПсына муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып барырга вәкаләтле җаваплы хезмәткәр билгеләргә.» сүзләренә алмаштырырга.;

1.2. Карарның 3 пунктында:

«баш белгечкә (юристка)» сүзләреннән соң «, ә ул булмаганда башлыкны» сүзләрен өстәргә;

«һәм Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының эшләре белән идарә итүчесе» сүзләрен «районның Башкарма комитетын, районның ПИЗОсын, районның ФБПсын»;

1.3. Карарның 6 пунктында «баш белгечкә (юристка)» сүзләреннән соң «, ә ул булмаганда башлыкка» сүзләрен өстәргә;

1.4. Карарның 6.1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2.Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2016 елның 30 декабрендәге 21-112 номерлы карары белән расланган (2019 елның 16 декабрендәге 55-348 номерлы, 2023 елның 12 июлендәге 35-284 номерлы карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Нигезләмәнең 1.5 пунктында «баш белгеч (юрист)» сүзләрен «, ә ул булмаганда башлык» сүзләре белән алыштырырга; .

2.2. Нигезләмәнең 2.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: .

«2.7. Реестрга муниципаль норматив хокукый актлар турында түбәндәге өстәмә белешмәләр кертелергә тиеш:

рәсми басылып чыгу чыганагы һәм датасы турында;

датасы күрсәтелгән хокукый экспертиза үткәрү турында;

прокурорлык реакциясе актлары турында;

регистрга җибәрү турында (порталда урнаштыру).»;

2.3. Нигезләмәгә 1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче кушымталарында «Документка үзгәрешләр кертү (гамәлдән чыгару)» баганасын бетерергә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru , «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга. http://novosheshminsk.tatarstan.ru/

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов